**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ ПСЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЕСӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

---

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

**2023 нче елның 15 нче февраленнән** **№ 73**

"Җир салымы турында"
Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Песәй авыл җирлеге Советының 2020
елның 25 февралендәге 138 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 263-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Песәй авыл җирлеге советы КАРАР КЫЛДЫ

1. «Җир салымы турында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге советының 2020 елның 25 февралендәге 138 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 карарның 4 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4. Календарь елның беренче кварталы, икенче кварталы һәм өченче кварталы салым түләүчеләр-оешмалар өчен хисап чоры дип таныла.

1.2 5 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәгечә бәян итәргә: “Салым түләүчеләр - оешмалар өчен салым түләү әлеге салым чорының беренче, икенче һәм өченче кварталы узганнан соң җир кишәрлегенең кадастр бәясенең процент өлешен җир кишәрлеге кадастр бәясенең процент ставкасы күләмендә, узган хисап чорыннан соң килә торган айның 28 нче числосыннан да соңга калмыйча, тиешле салым ставкасы күләмендә аванс түләүләре белән башкарыла дип билгеләргә Салым чоры йомгаклары буенча түләнергә тиешле салым суммасы үткән салым чорыннан соң килүче елның 28 февраленнән дә соңга калмыйча түләнә.».

Салым физик затлар салым түләүчеләр тарафыннан узган салым чорыннан соң килүче елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча түләнергә тиеш.».

2. " Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Советының 2020 елның 18 декабрендәге 16 номерлы " 2020 елның 25 февралендәге 138 номерлы Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Советының "Җир салымы турында карарына үзгәрешләр кертү турында" карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http://mendeleevsk.tatarstan.ru) « Песәй авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам

Менделеевск муниципаль районы
Песәй авыл җирлеге Советы рәисе В.И.Мөхәммәтгалеев